

Мордовиядә уза торган  XII Ботенроссия авыл Сабан туенда юртак токымнары чабышларында жайдак-всадник Илсур Галимжанов «Вернблум Аш» кушаматлы ат белән жинv яулады. Малнын хужасы – Рәмис Айзатуллов.
Жинvчеләргә топ приз – Лада машинасы белән кубокны Мордовия Республикасы башлыгы Артем Здунов һәм Татарстан Республикасы Президенты Ростәм Миннеханов тапшырдылар. Мордовия жайдагы Сергей Матвеев оченче урынны яулады.

XII Ботенроссия авыл Сабантуе призы ат токымнары арасында Татарстаннан «Вымпел» кушаматлы айгырга һәм 17 яшьлек жокей Минур Нуретдиновка бирелде. Хужасы - Рәмис Мингасин. Призны Мордовия Республикасы Авыл хужалыгы һәм азык-толек министры Александр Кечайкин тапшырды.
Мордовия Республикасы Башлыгы призына узышнын финалына 8 юртак керде. Алар арасында узышлар фавори-ты «Билли Флинн» һәм анын жайдагы – халыкара класслы мастер Геннадий Большаков та бар иде. Сvз унаеннан, жайдаклар арасында ир-атлардан тыш, юртаклы атлар чабышында бер кыз - Марина Ермилова катнашты. Кызганычка каршы, ул финалга узмады.
Узышларда 4 яшьтән олкәнрәк атлар катнашты. Аларга 1600 метр - әйләнә ярым дистанцияне узарга кирәк иде. Жайдаклар һәм атлар Мордовия, Татарстан, Чуашстан, Пенза олкәсеннән. Заездларны Татарстан Республикасыннан Ботенроссия категорияле профессио-наль судьялар хокем итте. Алар Мордовиядә ипподромнын идеаль юлын, шулай ук атларны тоту очен менә дигән шартларны билгеләп vттеләр. Мона Ләмберә районы Аксёново авылы янындагы кырда махсус 520 тамашачыга исәпләнгән трибуналы ипподром корылган булуы сәбәпчедер. Объектны тозvдә Мордовия тозvчеләренә Казаннан белгечләр ярдәм иткән.
Гомер-гомергә татарлар ат ярата һәм бvген шуна дәлил: Сабантуйларны кvпләр ат чабышы һәм корәшне кvзәтер очен генә дә котеп алуы сер тvгел. Бар халык Сабантуйга агылганда инде иртәнге сәгатьләрдән килеп, малкайларны чабышка әзерли торган жайдакларны да, атларнын хужаларын да, чабыш атлары-на гына хас vзенчәлекләре булган атларны да кvреп булды.

